**Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге башкарма комитеты**

# КАРАР

**«31» гыйнвар 2022 ел** **№2**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары, «Татарстан Республикасында «Җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авылы башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Түбән Өскебаш авыл җирлегендә 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегенең 2021 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы карарын 2022 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче Н.М.Мөхәммәтҗанов

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 2 номерлы карарына 1 нче кушымта

**2022 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегендә җирләү буенча исемлектәге гарантияләнгән хезмәтләрнең хакы**

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү хакы (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2974,19 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен) зиратка илтү | 957,14 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3033,35 |
| **Барлыгы** | **6964,68** |

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 2 номерлы карарына 2 нче кушымта

**2022 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегендә җирләү буенча исемлектәге гарантияләнгән хезмәтләрнең хакы**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү хакы (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү (киендерү) | 125,22 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2848,98 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен) зиратка илтү | 957,13 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3033,35 |
| **Барлыгы** | **6964,68** |